

# Габдулла Тукай

1886 нчы елның 26 нчы апрелендә туа.

Кечкенә Габдулла ятим кала.

Габдулла төрле гаиләләрдә үсә. Ул бик күп авырлыклар күрә.

Габдулла Тукай укырга ярата, яхшы укый, шигырьләр яза. Ләкин бик аз яши. 1913 елның 15 апрелендә үлә.

**Хәзер Габдулла Тукай – зур шагыйрь**

Маленький
Тукай.






**Тётя Тукая-
Сажида.**

Сажида ухаживает за больным Тукаем.







Малайлар укыган мәдрәсә



Тукай в деревенской медресе.



# Тукаевларның музей-йорты





***... Тау башына салынгандыр безнең авыл,***
***Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;***
***Авылыбызның ямен, суын тәмен беләм,***
***Шуңа күрә сөям жаным, тәнем белән.***

Г. Тукай 1886 нчы елның 26 нче апрелендә Арча районы Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Биредә сабыйга ата-ана мәхәббәте бик кыска гына вакыт эчендә кала: ул дөньяга килүгә биш ай да үтми, әтисе вафат була. Әнисе Мәмдүдәне Сосна мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча тәрбиягә калдыралар. Бераздан үз әнисе Габдулланы яңа гаиләсенә алдыра. Әмма бер елдан, 1890 елда Мәмдүдә ханым да үлеп китә. Бала бөтенләй ятим кала. Әнә шуннан шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана.

Бала чакта ук ана мәхәбәтеннән мәхрүм булып, җылы кул сыйпавын күрмәгән һәм тамагы ашка туймаган сабыйның кулдан-кулга, кешедән-кешегә күчеп йөрү еллары аның күңелендә төзәлмәслек яра калдыралар. Шуңа күрә дә Тукай иҗатында бәхеткә, мәхәббәткә сусау хисләре, йөрәк тетрәткеч шигырь юлларына әвереләләр.


# Габдулла Тукайның әсәрләрен балалар яратып укый.









## « Шүрәле»



## «Су анасы»



# «Кызыклы шәкерт» әсәре

- Әйдәле, Акбай! өйрән син,
  Арт аягың берлә тор;

Аума, аума! Туп-туры тор,

Төз утыр, яхшы утыр!

- Ник газаплыйсың болай син?

Мин әле бик кечкенә;

Мин туганга тик ике айлап
Булыр, йә өч кенә.

- Юк, кирәкми, мин өйрәнмим,

Минем уйныйсым килә;

Шул болыннарда ятасым,
Шунда ауныйсым килә.

- - Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй,

Зурайгач җайсыз ул;

Картаеп каткач буыннар,

Эш белү уңайсыз ул!



# «Бишек җыры»

- Әлли-бәлли итәр бу,
- Мәдрәсәгә китәр бу,
- Тырышып сабак укыгач,
- Галим булып җитәр бу.
- Йокла, угълым, йом күзең,
- Йом, йом күзең, йолдызым;
- Кичтән йокың кала да,
- Егълап үтә көндезең.
- Әлли-бәлли көйләрем,
- Хикәятләр сөйләрем,
- Сиңа теләк теләрем,
- Бәхетле бул диярем.
- Гыйззәтем син, кадрем син,
- Минем йөрәк бәгърем син,
- Куанычым, шатлыгым
- Тик син минем, синсең, син!






# Габдулла Тукайның исеме үлемсез

